| МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

15.03.2016 ел Казан ш. № 37/2-пр

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2016 елның 29 мартында теркәлде, № 3250

Игенчелек өлкәсендә Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә категорияләр бирү турында

Игенчелек өлкәсендә нәтиҗәле эшләүче авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләрен билгеләү һәм “2016 елда үсемлекчелек өлкәсендә тәгаен чыгымга бәйле булмаган ярдәм күрсәтү өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирү тәртибе” ягыннан “2016 елда агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында” 14.03.2016 ел, №138 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын үтәү йөзеннән, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының игенчелек тармакларын үстерү бүлеге начальнигы В.Л.Новичковка Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә категорияләр ( алга таба – категорияләр) бирүэшен оештырырга.

2. Расларга:

Игенчелек өлкәсендә Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә категорияләр бирү турында нигезләмәне (№1 кушымта);

Категория бирүгә заявка формасын (№2 кушымта);

Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы оешмаларында эшләрнең торышын бәяләү акты формасын (№3 кушымта);

Татарстан Республикасы муниципаль районында Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы оешмалары буенча игенчелек эшләре торышын бәяләүнең җыелма акты формасын (№4 кушымта);

Татарстан Республикасы буенча авыл хуҗалыгы культураларын ашлык берәмлекләренә күчерү коэффициентларын (№5 кушымта).

3. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары И.Х.Габдрахмановка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Премьер-министры
урынбасары – министр М.Г.Әхмәтов

ТР Авыл хуҗалыгы һәм
азык-төлек министрлыгының
15.03.2016 ел, №37/2-пр
боерыгына
№1 кушымта

## Игенчелек өлкәсендә Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә категорияләр бирү турында нигезләмә

1. Бу Нигезләмә үсемлекчелек продукциясен җитештерүне арттыру өчен сөрүлек җирләрдән нәтиҗәле файдалану хисабына нәтиҗәле эшләүче Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләрен (алга таба – оешмалар) ачыклау максатыннан чыгып эшләнде.

2. Игенчелек торышын бәяләү акты буенча 85тән артыграк балл туплаган оешмаларга – I категория, 60тан 84 баллга кадәр – II, 60тан кимрәк балл туплаган оешмаларга – III категория бирелә.

3. Категория бирү өчен Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының муниципаль районнардагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренә (алга таба – Министрлык, Идарә), оешмада игенчелек эшләре торышын бәяләү акты (алга таба - Акт) белән гариза тапшырган оешмалар карала. Гаризаларны кабул итүнең башлану һәм тәмамлану сроклары Министрлык боерыгы белән раслана. Әлеге мәгълүмат, гаризаларны кабул итүнең башлануына ким дигәндә 10 көн кала, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә “Татарстан Республикасы рәсми порталы” Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы составына кергән, Министрлыкның рәсми сайтына (алга таба - Сайт) урнаштырыла.

Акт оешмалар тарафыннан түбәндәгеләр нигезендә тутырыла:

категория бирелү елына кадәрге елда авыл хуҗалыгы культуралары уңышын җыю турында хисап нигезендә булдырылган, авыл хуҗалыгы культураларының чәчүлек мәйданнары турында мәгълүмат;

категория бирелү елына кадәрге соңгы 5 елда чәчү һәм уңыш җыеп алу йомгаклары турында хисаплар нигезендә булдырылган, субсидияләр алу елына кадәр килгән елда файдаланылган карт күп еллык үлән чәчүлекләренең булуы турында мәгълүмат;

күчерү коэффициентлары нигезендә ашлык берәмлекләренә күчерелгән, категория бирелү елына кадәрге елда авыл хуҗалыгы культуралары уңышын җыю турында мәгълүмат;

“Россия авыл хуҗалыгы үзәге” федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалы мәгълүматлары нигезендә, категория бирелү елына кадәрге елда уңыш җыеп алу өчен чәчелгән бөртек, бөртекле-кузаклы һәм ярма культуралары орлыклары турында мәгълүмат;

“Татарский” агрохимия хезмәте үзәге” федераль дәүләт бюджет учреждениесе яки “Әлмәт” агрохимия хезмәте станциясе” федераль дәүләт

бюджет учреждениесе тарафыннан расланган, категория бирелү елына кадәрге елда авыл хуҗалыгы культуралары уңышы өчен минераль ашламалар кертү турында мәгълүмат.

4. Категория бирү турында гариза, кергән көнне, журналда теркәлә (тапшыру чираты тәртибендә). Журнал битләренә номер сугылган, тегелгән һәм Идарә мөхере белән расланган-беркетелгән булырга тиеш.

5. Оешмалар җитәкчеләре, закон нигезендә, тапшырылган документларының дөреслегенә җавап бирә.

6. Идарәләр, оешмалар тарафыннан тапшырылган документлар һәм мәгълүматлар нигезендә, оешмалар тапшырган категорияләр бирүгә гаризаларны һәм актларны карап тикшергәннән соң Министрлыкка, Министрлык боерыгы белән расланган срокларда, Татарстан Республикасы муниципаль районында оешмалар буенча Игенчелек эшләре торышын бәяләүнең җыелма актын тапшыра.

7. Гаризаларны вакытында тапшырмаган оешмаларга III категория бирелә.

8.Идарәләр тарафыннан, оешмаларга категория бирү өчен Игенчелек эшләре торышын бәяләүнең җыелма актын төзегәндә, җитештерелгән үсемлекчелек продукциясе күләме (гектарыннан җыеп алынган ашлык берәмлегендә чагылдырылган), чәчелгән бөртек, бөртекле-кузаклы һәм ярма культуралары орлыклары күләме, бөртекле-кузаклы культураларны игү мәйданы, 1-4 ел дәвамында файдалануда булган күп еллык үлән мәйданы, май культуралары (көнбагыштан тыш) мәйданы, шулай ук категория бирелү елына кадәрге елда чәчүлекнең 1 гектарына кертелгән минераль ашлама күләме (тәэсир итү матдәсе күрсәткече нигезендә) исәпкә алына.

9. Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә категорияләр (алга таба – категорияләр) ел саен, категория бирелү елына кадәрге ел йомгаклары буенча, Министрлык боерыгы белән расланган срокларда бирелә.Бирелгән категорияләр нигезендә оешмалар рейтингы төзелеп, рейтинг Министрлык тарафыннан раслана.

10. Министрлык комиссия булдыра һәм аны, боерык нигезендә, кимендә 9 кешелек итеп раслый. Комиссия рәисеннән, рәисе урынбасары, секретареннән (тавыш бирү хокукына ия була алмый) һәм конкурс комиссиясе әгъзаларыннан тора.

10.1. Комиссия рәисе:

комиссия эшчәнлегенә җитәкчелек итә һәм үзенә йөкләнгән бурычларны үтәүгә җавап бирә;

комиссия әгъзалары арасында бурычларны бүлә;

комиссия утырышларын алып бара;

Утырышлар беркетмәләрен әзерләүне һәм комиссия тарафыннан кабул ителә торган карарларны тормышка ашыруны контрольдә тота.

10.1.1. Комиссия рәисе урынбасары, рәис югында, комиссия утырышында

аның бурычларын үти.

10.1.2. Комиссия секретаре:

Җыелма актларны кабул итүне һәм, керү тәртибендә,  заявкларны теркәүгә алу журналында теркәүне оештыра. Журнал битләренә номер сугылган, тегелгән һәм комиссия сектретаре мзасы һәм Министрлык мөхере белән расланган-беркетелгән булырга тиеш;

җыелма актларны кабул итү төгәлләнгәннән соң биш эш көне эчендә җыелма реестр булдыра һәм аны комиссиягә карап тикшерүгә тапшыра;

комиссия беркетмәсе алынганнан соң ике эш көне эчендә комиссия утырышларының көн тәртибе буенча материаллар әзерли, комиссия әгъзаларының утырышларда катнашуын тәэмин итә;

комиссия утырышы тәмамланганнан соң ике эш көне эчендә рейтинг нәтиҗәләрен Сайтка урнаштыра.

11. Комиссия карары белән килешмәгән очракта, оешма, карар Министрлык сайтына урнаштырылганнан соң 10 көн эчендә язмача гариза тапшырып, үзенә бирелгән  категориягә шикаять белдерүгә хокуклы.

Мөрәҗәгать итүченең гаризасы, комиссиянең чираттагы утырышында әгъзаларының тавыш бирү юлы белән, карала һәм аның нәтиҗәсе комиссия утырышы беркетмәсендә теркәлә. Бу хакта мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә.

ТР Авыл хуҗалыгы һәм
азык-төлек
министрлыгының
15.03.2016 ел, №37/2-пр
боерыгына №2 кушымта

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры М.Г.Әхмәтовка

___________________________дән
(вазыйфасы, оешма атамасын күрсәтеп)

__________________________________________
(ФИО)

Урнашу урыны:
_______________________________
_______________________________

ГАРИЗА

__________________________________________________________(алга таба - оешма)
(оешма атамасы, оештыру-хокукый формасын күрсәтеп)

_____________________________________________ аша Сездән,
(вазыйфасы һәм фамилиясе)

Игенчелек өлкәсендә Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә категорияләр бирү турында нигезләмәгә һәм Татарстан Республикасы агросәнәгать оешмаларында игенчелек эшләре торышын бәяләү актына туры китереп, ____________________ тиешле категория бирүегезне сорый.
(оешма атамасы)

_____________ _______________ «____» __________ 20__ ел
(имза) (ФИО)

Мөхер (булганда)

ТР Авыл хуҗалыгы
һәм азык-төлек
министрлыгының
15.03.2016 ел, №37/2-
пр боерыгына №3
кушымта

Татарстан Республикасы муниципаль районының

________________________ ________________________

(оешма атамасы) (район атамасы)

игенчелек эшләре торышын бәяләү акты

| № п/п | Күрсәткеч атамасы | Күрсәткеч | Баллардагы бәя |
|---|---|---|---|
| 1 | Ашлык берәмлекләрендә (центнер/гектар) чагылдырылган, авыл хуҗалыгы культураларының уңышы<br>(республика күрсәткече 50 баллга тигез, ашлык берәмлегенең һәр центнерының республика буенча уртача күрсәткечтән тайпылуы «+» яки «-» 5 балл) | | |
| 2 | Югары репродукцияле орлыклар (оригиналь орлыклар (ОС)+ элита орлыклары (ЭС)+ 1-3нче ел файдалануда булган репродукцияле орлыклар (РС1-РС3) чәчелгән бөртек, бөртекле-кузаклы һәм ярма культуралары мәйданы:<br>10 балл – югары репродукцияле орлыклары 85 %тан артыграк булганда;<br>5 балл – 75 - 85 %;<br>0 баллов – 75 % тан кимрәк. | | |
| 3 | Күп еллык үләннәр структурасында 1-4нче ел файдаланудагы үләннәрнең өлеше:<br>10 балл – 1-4нче ел файдаланудагы үләннәрнең өлеше 80%тан ким булмаганда;<br>0 балл – 80% тан кимрәк. | | |
| 4 | Ашлык кырларында бөртекле-кузаклы культураларның мәйданы:<br>5 балл – ашлык кырларында бөртекле-кузаклы культураларның мәйданы 5% һәм аннан күбрәк булганда;<br>0 балл – 5% тан кимрәк. | | |
| 5 | Чәчүлекләрдә май культураларының (көнбагыштан тыш) мәйданы:<br>5 балл – чәчүлекләрдә май культураларының (көнбагыштан тыш) мәйданы 5% һәм аннан күбрәк булганда;<br>0 балл – 5% тан кимрәк булганда. | | |
| 6 | Чәчүлекләргә минераль ашламалар кертү (кг д.в./га)<br>10 балл – 40 кг.д.в./га артыграк һәм аннан күбрәк кертелгәндә;<br>0 балл – 40 кг д.в./га кимрәк кертелгәндә. | | |

| | | |
|---|---|---|
| Хуҗалык буенча максималь балл**:** | | |

Искәрмә: 85 һәм аннан күбрәк балл тупланганда – I категориядәге оешма, 60-84 балл - II категориядәге оешма, 60тан кимрәк - III категориядәге оешма.

Дөреслеген раслыйм:

Оешма җитәкчесе: ____________________ (имза) ______________ (ФИО)

Баш агроном: ____________________ (имза) ______________ (ФИО)

Баш бухгалтер: ____________________ (имза) ______________ (ФИО)

дата______________

мөһер (булганда)

ТР
Авыл хуҗалыгы һәм
азык-төлек
министрлыгының

15.03.2016 ел, №37/2-
пр боерыгына
№4
кушымта

# Татарстан Республикасы ___________________________ муниципаль районында агросәнәгать оешмалары буенча игенчелек эшләре торышын бәяләүнең җыелма акты

| № п/п | Агросәнәгать комплексы оешмасы атамасы | Чәчүлек мәйданы, гектар (га) | Бәяләү күрсәткечләре атамасы | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Ашлык берәмлекләрендә (центнер/гектар) чагылдырылган, авыл хуҗалыгы культураларының уңышы (республика күрсәткече 50 баллга тигез, ашлык берәмлегенең һәр центнерының республика буенча уртача күрсәткечтән тайпылуы «+» яки «-» 5 балл) | | Югары репродукцияле орлыклар (оригиналь орлыклар (ОС)+ элита орлыклары (ЭС)+ 1-3нче ел файдаланууда булган репродукцияле орлыклар (РС1-РС3) чәчелгән бөртек, бөртекле-кузаклы һәм ярма культуралары мәйданы: 10 балл – югары репродукцияле орлыклары 85 %тан артыграк булганда; 5 балл – 75 - 85 %; 0 баллов – 75 % тан кимрәк. | | | | Ашлык кырларында бөртекле-кузаклы культураларның мәйданы: (5 балл – 5% һәм аннан күбрәк булганда; 0 балл – 5% тан кимрәк). | | | Күп еллык үләннәр структ 1-4нче ел файда үләннәрнең өлеше: (10 балл – 80%тан ким бул 0 балл – 80% тан кимрәк. | | |
| | | | ашлык берәмлеге центнер/га (ц.з.ед) | баллар (50+(хуҗалык уңышы ц.з.ед./га ТР буенча уртача уңыш – ц.з.ед./га )*5)) | Мәйданы, га | | % | балл | га | % | балл | Күп еллык үләннән мәйданы, га | | % |
| | | | | | бөртеклелләрнең | шул исәптән югары репродукцияле орлык чәчелгәннәре | | | | | | гомуми | шул исәптән 1-4 – нче ел файдаланудагы | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
| | | | | | | | | | | | | | | |
| Муниципальному район буенча уртача балл: | | | | | | | | | | | | | | |

Мәгълүматларның дөреслеген раслыйбыз:

ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының ТР муниципаль районындагы ______ идарәсе началь.: __________ ____________
(имза) (Ф.И.О.)

Игенчелек буенча консультант: _________ ____________
(имза (Ф.И.О.)

Мөһер

«Россельхозцентр» ФГБУның ТР ф
муниципаль районындагы_______бу
Мөһер

«ЦАС «Татарский» или «СА
ФГБУның муниципаль районндагы б
Печать

ТР Авыл хуҗалыгы һәм
азык-төлек
министрлыгының
15.03.2016 ел, №37/2-пр
боерыгына
№5кушымта

Татарстан Республикасы буенча авыл хуҗалыгы
культураларын ашлык берәмлекләренә күчерү коэффициентлары

| № п/п | Авыл хуҗалыгы культуралары | Күчерү коэффициентлары |
|---|---|---|
| 1 | Бөртекле | 1,0 |
| 2 | Бөртекле-кузаклы | 1,2 |
| 3 | Бөрteккә кукуруз | 1,3 |
| 4 | Шикәр чөгендере | 0,16 |
| 5 | Бәрәңге | 0,2 |
| 6 | Яшелчә | 0,2 |
| 7 | Җиләк-җимеш культуралары | 1,2 |
| 8 | Май культуралары (рапс, рыжик, соя, көнбагыш һәм башка культуралар) | 1,5 |
| 9 | Күп еллык үләннәр, шул исәптән: | |
| | орлыкка | 10,0 |
| | печәнгә | 0,50 |
| | яшел азыкка, сенажга (яшел массаның авырлыгы) | 0,18 |
| 10 | Азыкка кукуруз (яшел массаның авырлыгы): | |
| | яшел азыкка | 0,17 |
| | силоска | 0,26 |
| 11 | Бер еллык үләннәр, шул исәптән: | |
| | печәнгәяшел азыкка, сенажга (яшел массаның авырлыгы) | 0,40 |
| | яшел азыкка, сенажга (яшел массаның авырлыгы) | 0,18 |
| 12 | Силоска азык культуралары ((яшел массаның авырлыгы) | 0,17 |
| 13 | Тамыразыклар (терлек азыгы) | 0,16 |
| 14 | Сүсле җите, шул исәптән: | |
| | орлыкка | 1,65 |
| | җепселгә | 3,85 |
| | саламга | 0,41 |